Республика Татарстан Совет Иляксазского сельского поселения Сармановского муниципального района	Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Советы

РЕШЕНИЕ
31.03.2026

КАРАР
№21

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 N 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Сарман муниципаль районының «Илексазское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге советы карарына (28.05.2015 N 10, 20.06.2018 N 8, 19.11.2018 N 24, 18.03.2020 N 3, 01.11.2024 N 11, 22.11.2024 N 20А, 16.12.2025 № 10, 30.12.2025, № 16) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2 пунктындагы 2.4.3 пунктчасында «, билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;».

2. Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 18 декабрендәге 15 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Совет рәисе
Илексаз авыл җирлеге
Сарман муниципаль районы
Татарстан Республикасы

И.Х.Хадиуллин